Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

13 июль 2022 ел № 158

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 28 декабрендәге 145 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 21 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 28 декабрендәге 145 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 30 мартындагы 166 номерлы, 2017 елның 05 маендагы 178 номерлы, 2017 елның 31 маендагы 184 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 196 номерлы, 2018 елның елның 11 маендагы 238 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 267 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 284 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 366 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 398 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 14 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 96 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

а) 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы җиденче абзацын «муниципаль хезмәт вазыйфасы» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хокукый актларда муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларына «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кергән очракта (урта гомуми белем булган очракта) күрсәтелмәскә мөмкин.»;

б) 6 бүлегенең 6.5 пунктын «Муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр» төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т. Д. Нагуманов